ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г. Казань Боерык

27.10.2021 № 329- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 декабрендәге 996 номерлы карары белән расланган административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 4 өлеше һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә белән туры килеп боерам:

1. Кушылып бирелгән Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларының исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең 2014 ел, 10 сентябрь, 130-од номерлы «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә һәм хайваннар дөньясы объектларын һәм алар яшәү мохитен саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар турында эшләр башкаруны тәэмин итүнең башка чараларын кулланырга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары турында»гы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Ю.Б. Матвеевка әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Рәис Ф. С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик
ресурслар буенча
дәүләт комитетының
27.10.2021 ел 329-од номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасарлары (алга таба – Дәүләт комитеты);

Дәүләт комитеты Идарәләренең башлыклары;

Дәүләт комитеты бүлекләре башлыклары;

Дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясын һәм аеруча саклаулы табигый территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлек башлыклары;

Дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясын һәм аеруча саклаулы табигый территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлек җитәкчеләре;

региональ әһәмияттәге дәүләт табигый тыюлыкларның башлыклары;

Дәүләт комитетының әйдәп баручы киңәшчесе;

Дәүләт комитетының әйдәп баручы консультанты;

Дәүләт комитетының белгечләре (барлык категориядә).